# МАЛАЙЛАР ГЫНА ДИМӘГЕЗ

Малайлар гына димәгез
Без булачак ир егет
Президентлар  геройлар да
Булганнар безнең кебек.

*Кушымта:*
Укыйбыз да, өйрәнәбез,
Шаярабыз, уйныйбыз,
Сезнең кебек бик серьезный
Булырбыз дип уйлыйбыз.
Ля-ля-ля......

Компьютерларда уйныйбыз
Техника заманасы,
Үсәбез без чын ир булып
Туган ил таянасы!!!!

*Кушымта*

Малайлар гына димәгез
Без булачак ирләр дә
Безнең кулларга калачак
Ил киләчәк көннәрдә!!!